**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.07.2024 г. Казань № 82од

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуларының Татарстан Республикасы юстиция министрының 2020 елның 7 февралендәге 22од номерлы боерыгы белән расланган тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«8.Гариза теркәлгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча җаваплы зат гражданлык хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешма белән түләүсез нигездә идарә итүгә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен министр каравына бәяләмә һәм башка материаллар белән тулыландырылган гаризаны тапшыра»;

түбәндәге эчтәлектәге $8^1$ пунктны өстәргә:

«$8^1$. Җаваплы затның гражданлык хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешма белән түләүсез нигездә идарә итүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында бәяләмә әзерләве өчен, шулай ук министр тарафыннан рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган шартлар барлыкка килү нигез булып тора.»

Министр Р.И. Заһидуллин